**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2473**
**19.04.2024**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 23 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 пунктның 13 пунктчасы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләү эшен оештыру турында» 2017 елның 21 апрелендәге 2465 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3841 номерлы, 2019 елның 28 июнендәге 3288 номерлы, 2022 елның 1 сентябрендәге 4429 номерлы, 2022 елның 2 ноябрендәге 6061 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Җирләү урыннарына килү өчен тәкъдим ителә торган вакыт – көн саен 08.00 дән 17.00 гә кадәр.

Зират администрацияләренең эш режимы – көн саен 08.00 дән 17.00 гә кадәр.

Яр Чаллы шәһәре зиратларында вафат булганнарны җирләү өчен тәкъдим ителә торган вакыт көн саен - 08.00 дән 16.00 гә кадәр.»;

2) 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Зират территорияләрендә, вафат яки һәлак булганнарны аларның диненә туры китереп чардугансыз ысул белән җирләү өчен, аерым участоклар яки секцияләр булдырылырга мөмкин.»;

3) 63 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«63. Кабер казу 08.00 дән 15.00 гә кадәр гамәлгә ашырыла.»;

4) 90 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урнаштырыла торган кабер өсте корылмаларының биеклеге - 170 (бер йөз җитмеш) сантиметрдан артык түгел.»;

5) 92 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Зиратларда кабер өсте корылмаларын урнаштыру җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт көче белән яки Вәкаләтле орган рөхсәте буенча, эшләр башланганчы һәм алар тәмамланганнан соң Вәкаләтле орган белгечләре тарафыннан аларны урнаштыру буенча эшләрне башкару технологиясенә контрольне гамәлгә ашырып, башка затлар тарафыннан көн саен 08:00 дән 17:00 гә кадәр башкарыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов